**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Глава**
**Карамалинского сельского**
**поселения Азнакаевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**Карамалы авыл**
**җирлеге Советы башлыгы**

ул. Центральная, д. 8, село Карамалы,
Азнакаевского муниципального района,
423301, Тел. (факс) (8-5) 45-6-42

Үзәк урам, 8, Карамалы авылы
Азнакай муниципаль районы, 423301
Тел. (факс) (8-292) 45-6-42

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«15» март 2022 ел №2

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Советының «Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең 2021 ел өчен бюджет үтәлеше турында»гы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге халкының Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Советының«Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең 2021 ел өчен бюджет үтәлеше турында»гы карары проекты буенча фикер алышуда катнашу хокукларын саклау максатыннан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» дип исемләнгән 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы нигезендә, халык алдында тыңлаулар үткәрү юлы белән Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20нче статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Советының 2012 елның 19 апрелендәге 34нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге халык алдында тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә таянып, **карар итәм**:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Советының «Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең 2021 ел өчен бюджет үтәлеше турында»гы карары проекты (1нче кушымта) буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2.Халык тыңлауларын үткәрү инициаторы булып Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге башлыгы тора.

3.Билгеләү:
- уздыру вакыты - 2022 елның 08 апреле 10.00 сәгатьтә;

- үткәрү урыны - Карамалы авылы мәдәният йорты;
- әлеге мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кабул ителә торган адрес: 423301, ТР, Азнакай районы, Карамалы авылы, Яшьлэр урамы, 3.

4.Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Советының «Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең 2021 ел өчен бюджет үтәлеше турында»гы карары проекты буенча гамәлдәге законнар, Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең норматив хокукый актлары нигезендә һәм әлеге карар нигезендә билгеләнгән срокларда тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.

5.Әлеге карарны һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Советының «Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең 2021 ел өчен бюджет үтәлеше турында»гы карары проектын (1нче кушымта) 2022 елның 17 мартыннан да соңга калмыйча Карамалы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

Башлык А.Р.Ногманов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЗНАКАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
КАРАМАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
КАРАМАЛИНСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ